КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 май г.Казань № 375

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы мәсьәләләре» 2006 ел, 22 февраль, 68 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 ел, 10 июль, 348 нче; 2007 ел, 20 апрель, 136 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2013 ел, 2 февраль, 69 нчы; 2013 ел, 24 июнь, 436 нчы; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2016 ел, 20 февраль, 103 нче; 2016 ел, 6 август, 536 нчы; 2017 ел, 15 июль, 497 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2017 ел, 28 декабрь, 1070 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1126 нчы; 2017 ел, 12 май, 350 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктта «матди-техник тәэмин итүне» дигән сүзләрдән соң «һәм җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне» дигән сүзләр өстәргә;

4.1.36 нчы пукнтта «кадрлар белән тәэмин итүне» дигән сүзләрдән соң «, җәмәгать судьялары аппаратлары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне» дигән сүзләр өстәргә.

2. Бу карар 2018 елның 18 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин